СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино,
Арский муниципальный район, 422014

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле
авылы, Арча муниципаль районы,
422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы карары**

**27 апрель 2023 ел** **№1**

**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районы**
**"Иске Чүриле авыл җирлеге"**
**муниципаль берәмлегенең**
**җирдән файдалану һәм төзелеш**
**кагыйдәләре проекты буенча**
**гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 - 33 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Уставы, 2019 елның 13 июнендәге 77 нче номерлы Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә (2021 елның 13 сентябрендәге 29 номерлы үзгәрешләр белән) нигезендә, авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән проектны тикшерүдә катнашу хокукын үтәү максатыннанн, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты (алга таба — Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты) буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. гавами тыңлаулар үткәрүне оештыручы-Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссия (алга таба-Комиссия);

2.2. гавами тыңлауларны үткәрү вакыты һәм урыны:

25.05.2023 ел, 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Яңа урам, 52 йорт адресы буенча Иске Чүриле мәдәният йортында;

2.3. җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә торган адрес - 422014, Татарстан Республикасы, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Яңа урам, 52 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы (дүшәмбе — җомга 8-00 сәгатьтән 12-00 сәгатькә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

2.4. җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектының демонстрацион материаллары күргәзмә-экспозициясен оештыру - Иске Чүриле авыл җирлегендә яшәүчеләргә җиткерү максатыннан Татарстан Республикасы, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Яңа урам, 52 нче йорт адресы буенча урнашкан Иске Чүриле мәдәният йорты бинасында (дүшәмбе-җомга 8-00 сәгатьтән 12-00 сәгатькә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

3. Комиссиягә:

3.1. билгеләнгән тәртипкә ярашлы рәвештә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларны әзерләргә һәм үткәрергә;

3.2. гавами тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Арча район Советына гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар тәкъдимнәрен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен, шулай ук җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең эшләнгән (үзгәрешләр кертү очрагында) проектын тапшырырга;

3.3. 27.05.2023 елга кадәр җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (www.arsk.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (www.pravo.tatarstan.ru), Арча муниципаль районының рәсми сайтында (www.arsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Р.Т. Һидиятуллин